РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ФЕДОТОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ул.Советская, д.6, с.Федотовка
Лениногорский район,423295
Тел.:(85595) 3-28-25; 3-28-24
E-mail: Fed.Len@tatar.ru

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«ФЕДОТОВКА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы,6 нче йорт, Федотовка
Авылы, Лениногорск районы, 423295
Тел.: (85595) 3-28-25; 3-28-24
E-mail: Fed.Len@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ КАРАР**

**15.10.2018**
**№27**

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәй датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015елның 26 октябрендәге 9 номерлы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасының беренче абзацында «фатир» сүзләреннән соң «фатирлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 3 пунктчасының беренче абзацында «торак йортлары» сүзләреннән соң «торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 3 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт (административ бина); Федотовка авылы, Совет урамы, 8 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы); Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (авыл клубы бинасы); Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2017 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**«Федотовка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы,**
**Совет рәисе В.И. Павлова**